Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№6 (57)
7 март

12+



## 8 март белән!

**Хөрмәтле хатын-кызлар!**

Сезне Халыкара хатын-кызлар көне белән ихластан тәбрик итәм!

Әлеге яз бәйрәме үзе белән игелек һәм оптимизм алып килә; ул асыл затларның гүзәллеген, сөйкемлелеген һәм тормыш энергиясен гәүдәләндерә. 8 март көнне без хатын-кызларга, аларның әчкерсез ягымлы, игътибарлы һәм кайгыртучан булуларына сокланабыз. Бу бәйрәмнең тагын бер мөһим ягы шунда: ул хәзерге дөньяда хатын-кызның социаль дәрәҗәсе даими үсүен, иҗтимагый тормышның һәр өлкәсендә дә катнашып, уңышка ирешүен символлаштыра. Безнең коллектив хатын-кызларына университет үсешенә, фәнни һәм белем бирүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә, студентлар тәрбияләүгә кертқән бәяләп бетергесез хезмәтләре өчен чиксез рәхмәт әйтәсе килә. Сезнең иҗади энергия һәм югары профессионализмыгыз алдында баш иябез һәм, иң әһәмиятлесе, үзегездәге назлылык, мөлаемлык, күңел юмартлыгын һәм гаилә традицияләрен саклауга җаваплы каравыгызны югары бәялибез.

Сезгә һәр эшегездә уңыш һәм иминлек телим! Бәхетле булыгыз!

**КФУ ректоры И.Гафуров**

## • Универ хәлләре

**5 МАРТТА** КФУ ректоры **ИЛШАТ ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Гадәттәгечә, административ эшләр буенча проректор, аппарат җитәкчесе **АНДРЕЙ ХАШОВ** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм атна дәвамында узачак вакыйгалар белән таныштырды. Алар арасында иң мөһимнәре – Күзәтүчәнлек советы һәм Татарстан республикасы Ректорлар советы утырышы. Алга таба мәгълүмат һәм элемтәләр департаменты җитәкчесе **ДМИТРИЙ БУРМИСТРОВ** һәм ректор киңәшчесе – иҗтимагый-мәгълүмати үзәк җитәкчесе **ЮРИЙ АЛАЕВ**, КФУ порталын алга җибәрү эшләре турында сөйләделәр. Аларның сүзләренә караганда, соңгы ике ай эчендә сайтка керүчеләрнең саны арткан. Юрий Алаев бу процессны тагын да камилләштерү өчен, сайтның беренче бите бизәлешен үзгәртү идеясе белән чыкты. Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **СЕРГЕЙ ИОНЕНКО** 2013 елгы кабул итү компаниясенә әзерлекнең барышы белән таныштырды. Ул университетның Ачык ишекләр көне нәтиҗәләре, мәгълүмат бирә торган буклетлар ясау, КФУның «Белем алу. Карьера» күргәзмәсендә катнашуы һәм Үзбәкстанга барып кайту турында сөйләде. Перспектив үсеш үзәге директоры **МИХАИЛ САВЕЛИЧЕВ** университет укытучыларының ротация оешмасы регламенты мәсьәләсенә тукталды. Ул регламент проектына КФУ бүлекчәләре тәкъдим иткән төзәтмәләрне җиткерде. Фәнни эшчәнлек буенча проректор **ДАНИС НУРГАЛИЕВ** РФ Хөкүмәте карары нигезендә оешкан югары уку йорты хезмәткәрләре һәм галимнәренең фәнни хезмәтләр бастырып чыгарудагы активлыкларын арттыру буенча проект эшчәнлеге белән таныштырды. Уку-укыту эшләре буенча проректор **РИЯЗ МИНЗАРИПОВ**, Яр Чаллы һәм Алабуга филиалларын КФУга кушу сәбәпле, аларның нигезләмәләренә үзгәрешләр кертү кирәклеге турында әйтте. Проректорның мөрәҗәгатен ректорат бер тавыштан кабул итте.

• • • •

Шушы көннәрдә Яр Чаллы филиалының **ИРЕКЛЕЛӘР АГЕНТЛЫГЫ** «Игелекле открытка» («Добрая открытка») акциясе кысаларында **РЕАБИЛИТАЦИОН ҮЗӘКТӘ ДӘВАЛАНУЧЫ БАЛАЛАР ЯНЫНДА БУЛДЫ**. Волонтерлар, балалар белән җырлап-биегәннән соң, үз куллары белән 8 мартка төрле бүләкләр ясап күрсәттеләр, кызыксынып карап утырган балалар үзләре дә «иҗат итү» процессында катнаштылар.

Ахыры 3нче биттә.



Алия Галимуллина фотосы

## Рөстәм Миңнеханов:
# «Безнең киләчәк монда!»

Динара **МИННЕКАЕВА**,
хәбәрче

26 февраль көнне Казан федераль университетына ТР президенты Рөстәм Миңнеханов һәм башка җитәкчеләр килде. Алар шулай ук Филология һәм сәнгать институты бинасында узган уку йортының Кайгыртучанлык советы күчмә утырышында да катнашты.

Җөмһүрият башлыгының университетка визиты Фундаменталь медицина һәм биология институтының Фәнни-белем бирү үзәге белән танышудан башланды. Париж коммунасы урамындагы бинада фәнни һәм укыту лабораторияләре урнашкан. Биредә бик күп фәнни тикшеренүләр үткәреләчәк. Заманча җиһазландырылган лабораторияләрне Рөстәм Миңнеханов югары бәяләде. «Лабораторияләр эшчәнлеген тизрәк юлга салу өчен, төзелеш эшләре белән беррәттән бүлмәләрне төзекләндерү эше дә башкарылды. Университет галимнәре төзүчеләр белән бергәләп эшләде», – диде ректор Илшат Гафуров.

Филология һәм сәнгать институтында республика җитәкчеләре төрле халыкларның теле, тарихы һәм мәдәнияте белән таныша алды. Татар теле һәм әдәбияты үзәгендә «Ана теле» программасы буенча татар теле дәресе бара иде. Бу программаны Кытайда да тыңлыйлар. Рөстәм Миңнеханов алар белән дә аралашты, фикерләрен белеште һәм күпмедер дәрәҗәдә белемнәрен дә тикшерде. «Ана теле» проектын башка илләрдә яшәүче милләттәшләребез дә туган телдә сөйләшерлек дәрәҗәгә җиткерергә кирәк», – диде президент.

Кунаклар шулай ук Гете ис. Немец теле һәм мәдәнияте, Британия мәдәнияте, Американы өйрәнү үзәкләре, халык өчен бушка уздырыла торган татар теле курслары эшчәнлеге белән таныште. Татар фольклоры үзәгендә Кайгыртучанлык советы әгъзалары игътибарына төрле экспедицияләр вакытында табылган халык музыка кораллары тәкъдим ителде. Студентлр хәтта аларның кайберләрендә милли көйләр дә уйнап күрсәтте. Русча субтитрлар белән эшләнгән «Шүрәле» мультфильмын караганда, күпләр балачагын искә төшергәндер. Институтның тагын бер горурлыгы: бик күп бәйгеләрдә җиңү яулаган милли костюмнар проекты. Кунаклар студентларның бу хезмәтен дә бик югары бәяләде. Оҗрашу истәлеге итеп, КФУның Кайгыртучанлык советы рәисе Р.Миңнехановка студентлар үз куллары белән эшләнгән бүләк – шәхси билге (тугра) тапшырды.

Совет утырышын президент ачып җибәрде. Башта ул күргәннәренә бәя бирәп нәтиҗә ясады. «Университетта бик зур үзгәрешләр бара. Республиканың да, предприятиеләрнең дә киләчәге биредә. Шуңа күрә бүгенге көндә безгә уку йортының үсешен камилләштерердәй юнәлешләрне кабул итәргә кирәк», – диде җитәкче. КФУ ректоры Илшат Гафуров үз чыгышында президентка рәхмәт сүзләре җиткерде.

Ахыры 2нче биттә.

## • Чара

# «Scopus»ка ничек эләгергә?

Ләйсән **ИСХАКОВА**,
Массакүләм коммуникацияләр
һәм социаль фәннәр институты

Кичә КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә «Журналларның бурычы һәм аларның «Scopus» системасына сайлап алыну критерийлары» дип аталган семинар-тренинг уздырылды. Аны техник фәннәр кандидаты, басмаларны «Scopus» мәгълүматлар базасына сайлап алу буенча экспертлар советы әгъзасы Ольга Кириллова (фотода) үткәрде.

Хәзерге заманда күпчелек гыйльми тикшеренүләрнең чыганагы булып циталалау индексы хезмәт итә. Бу – фәнни публикация һәм аларның цитаталануы турындагы мәгълүматны үз эченә сыйдырган библиографик база.

Ахыры 3нче биттә.



Диана Поварова фотосы

Хатирә

# Татарның милли кыңгыравы

Динә МӨХТӘСИПОВА,
хәбәрче

**Шушы көннәрдә КФУның татар филологиясе бүлегендә Аяз Гыйләҗевның 85 еллыгына багышланган әдәби кичә узды. Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай һәм РСФСРның М.Горький ис. Дәүләт бүләкләре, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый һәм С.Рәфыйков ис. әдәби премияләре иясе, Татарстанның, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Аяз Гыйләҗевның иҗади мирасы хаклы рәвештә XX-XXI йөз татар мәдәниятенең иң кыйммәтле хәзинәсе, әдәби-мәдәни байлыгы санала.**



Кичәдә катнашучылар Нәкыя апа Гыйләҗева белән. Зөлфия Хөснуллина фотосы.

Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында дөньяга килә. Язучының әдәби зәвыгын тәрбияләүдә әти-әнисенең язма-басма сүзгә ихтирамы, гаиләдә китап укуга аерым вакыт бүлүе әһәмияткә ия. Өченче класста кечкенә Аяз беренче шигырен яза. Дүртенче класста шигырь-поэмалар яза башлап, бишенчедә «Ул үскәндә» повестен «әмәлләргә тотына», күп санлы нәни пьесалар яза. Шулай итеп бөек татар язучысы, драматург Аяз Гыйләҗев язганнарын мирас итеп сөекле тормыш иптәше – мөгаллимә Нәкыя ханыма, уллары – татарның тарихчы галиме, академик, Казан (Идел буе) федераль университетының Тарих институтында бүлек мөдире Искәндәр Гыйләҗевка, татарны дөньякүләм танытуга зур өлеш керткән драматург, татар кино сәнгатен пропагандалауда армыйталмый эшләүче Мансур Гыйләҗевка, табиб, эшмәкәр Рәшат Гыйләҗевка, оныкларына, гомумән, бөтен татар халкына калдырды.

Аяз Гыйләҗев 1945 елда Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Ләкин ул: «Университет мин ашкынып-газапланып көткәннәрне бирмәде, үземне яшь чагымнан борчыган сорауларга җавап табу түгел, сорауларым тирәнәйделәр, ишәйделәр, авырая бардылар», – дип яза. Улларының укуны ташлап кайтуын ата-ана бер үпкә сүзе белдермичә кабул итә. Яшь егетнең күңеле һаман саен яңалык эзли. Язмышында бик күп гыйбрәтле хәлләргә тап була. 1948 елның көзендә яңадан университетка керергә тәвәккәлли. Бу дәвердә ул әдәбиятка ныклап керә башлый, әдәби түгәрәкләрдә, очрашуларда актив катнаша. Шундагы кызу бәхәсләр аны кулга алу өчен бер нигез булып тора. 1950 елның мартында ул кулга алына. Хөкем карары 7 елга «Исправительно-трудовые лагеря» дип чыгарыла. Җизказган, Көнгәр, Балхаш, Актас, Волынка – аның төрмә михнәтләре маршруты шундый. А.Гыйләҗев 1956 елның 13 февралендә аклана. Казанга кайтып, университетта укуын дәвам итә. 3 ел укыганнан соң, Казандагы белем йортын ташлап, Мәскәүдәге Югары әдәби курсларга китә.

А.Гыйләҗевның дистә еллар дәвамында тудырылган гаҗәеп киң кырлы, күп катламлы, жанр төрлелеге һәм тема ягыннан гаять бай әдәби иҗаты XX гасыр татар тормышының иҗади елъязмасы булып укыла, милли әдәбиятның гына түгел, дөнья әдәбияты үсешенең бер өлеше булып тора.Аяз Гыйләҗев – әдәбимәдәни дәверне яңарыш чорына алып кергән, милли үзаңны, фикер күтәрелешен әзерләгән, яшәү мәгънәсен милләткә хезмәттә күргән татарның милли кыңгыравы.

Чарада да гомере буе Аяз Гыйләҗев иҗатының ялкынында янып, аңа ярдәм итеп, аның өчен ут йотып яшәгән, бүгенге көндә дә аның мирасын мәңгеләштерү өстендә фидакарьләрчә олы гамәлләр кылучы, аның басылмаган хезмәтләрен җыю, бастыру, дөньяга таныту эше белән шөгыльләнүче әүлиядәй ак күңелле Нәкыя апа да катнашты. Ул Аяз абый белән бәйле хатирәләре белән уртаклашты.

Кунаклар арасында әдипнең ике повестен төрекчәгә тәрҗемә итеп, иҗатын Төркиядә таныткан галим Фатих бәй Котлы да бар иде. Ул Аяз абый белән ничек танышулары турында сөйләде. «Аяз абый – татар теле серләренә өйрәтүче минем остазым», – диде.

Аяз Гыйләҗевне искә алу кичәсе студентлар күңелендә озак сакланыр. Әле чара тәмамлангач та, башта коридорларда, аннары социаль челтәрдә аралашулар дәвам итте. Студентлар кичәне оештыручыларга, бигрәк тә Гөлфия Расил кызы Гайнуллинага рәхмәтле.

Аяз Гыйләҗевның иҗатын беренче президентыбыз М.Шәймиев та: «Аяз Гыйләҗев дигән язучы булмаса, татарның әдәби мирасы никадәр сай булыр иде», – дип бәяли. Ә без бу хәзинәне бер бөртеген дә югалтмыйча киләчәк буынга тапшырырга тиеш.

---

## Рөстәм Миңнеханов:
# «Безнең киләчәк монда!»

**Башы 1нче биттә.**



Алия Галимуллина фотосы

Көн тәртибендәге беренче мәсьәлә буенча Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры Андрей Киясов чыгыш ясады. Ул үзе җитәкли торган институт үсеше, Трансляцион медицина үзәген ачу, шулай ук уку йортындагы башка клиник базалар турында сөйләде. Утырышта катнашкан Медицина фәннәре академиясе әгъза-корреспонденты, РФ Федераль медико-биология агентлыгының Физика-химия институты вәкиле Вадим Говорун бу уңайдан үз теләк-тәкъдимнәрен җиткерде: «Мондый институтның үсеш программасын тормышка ашырганда, университет рухын югалтмаска кирәк. Тарихка кайту көтелмәгән нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Бу институт белән хезмәттәшлек итү – безнең өчен зур дәрәҗә. Проектның зур уңыш китерәчәгенә ышанам».

Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин КФУның ачык биофармацевтик технопарк проекты белән таныштырды. Проектны өч этапта тормышка ашырырга тәкъдим ителде. Тәүге этап 2013-2015 елларда беренче корпус ачуны күз алдында тота. 2014-2016 елларда, ягъни икенче этапта, икенче һәм өченче корпуслар сафка басачак. Соңгы этапта «Иннополис» Махсус икътисади зона ачу күздә тотыла. Биофармацевтик технопарк уку йортының рейтингы үсүгә, фәнни тикшеренүләр уздыру өчен күпсанлы тәкъдимнәр кабул итүгә, биомедицина һәм фармацевтика буенча белгечләр әзерләүгә китерәчәк. Президент та технопарк ачу идеясен хуплады.

Казан федераль университеты кампусынның кулланылыш мәйданын арттыру буенча шулай ук проректор Марат Сафиуллин чыгыш ясады. Әйтик, Химия институты ишек алдында яңа укыту корпусы төзү планлаштырыла. Бу уңайдан да җитәкче уку йортына ярдәм итәчәген белдерде.

Алдагы мәсьәлә Филология һәм сәнгать институты базасында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләре өчен телгә әзерләү хезмәтләренең бердәм пакетын формалаштыруга багышланды. Институт директоры, профессор Рәдиф Җамалетдинов милли телне, әдәбият-мәдәниятне саклауга ярдәм итәргә теләүчеләрнең артык күп булмавын әйтте. «Россия гуманитар фәнни фонды грантлар күләмен кыскарта. Татар филологиясе һәм мәдәнияте белгечләрен әзерләү, Татарстан һәм Башкортстан республикаларын исәпкә алмаганда, Россиянең башка вузларында бөтенләй алып барылмый. Бу проблемаларны күрмәсәк, без башта милли кадрлар әзерли торган фәнни мәктәпләрне, аннары тел һәм мәдәниятебезне югалтырга мөмкин. Казанны чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез үз башкалалары, ә президентны үз президентлары кебек кабул итәләр. Шуңа күрә бу мәсьәләләрне без хәл итәргә тиеш», – диде Рәдиф Җамалетдинов. Үз чыгышында филология юнәлеше буенча белгечләрнең соңгы урыннарда торуын хезмәт хакының түбән булуы белән дә аңлатты. Шулай ук конкурсның зур булмавын, БДИ нәтиҗәләре түбән булуны сәбәп итеп, министрлык кабул итүгә бәйле саннарны да кыскарта икән. Нәтиҗәдә уку йорты булган галимнәрен югалта, ә яшьләрне үзенә эшкә җәлеп итә алмый. «Без республика һәм Казан мәктәпләре белән актив хезмәттәшлек итәбез. Ләкин болар гына җитми. Сезнең ярдәм белән бердәм полилингваль челтәр булдыру, ягъни мәктәп укучыларына берничә тел өйрәтүне тормышка ашырырга телибез», – диде Рәдиф Җамалетдинов президентка мөрәҗәгать итеп. Ул шулай ук совет әгъзалары игътибарына халыкара «Tatarica» фәнни журнал проектын тәкъдим итте. Аны татар, рус һәм инглиз телләрендә чыгару планлаштырыла.

Бу көнне Казан федераль университеты берничә оешма белән килешү төзеде. «РИТЭК» Ачык акционерлык җәмгыяте белән фән һәм инновация өлкәсендә углеводородны табу һәм эшкәртү методларын өйрәнү буенча килешүгә кул куелды. «Ак Барс» Банк» ачык акционерлык җәмгыятенең бизнес-мәктәбе» уртак проектын ачу һәм тормышка ашыру буенча хезмәттәшлек турындагы килешүгә КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм ««Ак Барс» Банк» ААҖ рәисе Роберт Миннегалиев кул куйды. Татарстан республикасында һәм Идел буе округында белем бирү сыйфатын арттыру буенча озак сроклы хезмәттәшлек итү мәсьәләсе хәл ителде.

Утырыш ахырында Татарстан республикасының дәүләт бүләкләрен тапшыру тантанасы булды. «ТРның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә Идарә итү һәм территориаль үсеш институты директоры Наилә Баһаутдинова, Массакүләм коммуникация һәм социаль фәннәр институтының татар журналистикасы кафедрасы җитәкчесе Васил Гарифуллин, Физика институтының теоретик физика кафедрасы җитәкчесе Юрий Прошин, Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге директоры Рәис Шәйхелисламов ия булды. Икътисад һәм финанс институтының икътисад теориясе кафедрасы доценты Кафия Сафиуллинага «ТР югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре», юридик факультетның җинаять процессы һәм криминалистка кафедрасы доценты Станислав Якушинга «ТРның атказанган юристы» исеме бирелде. Социаль һәм тәрбия эшләре буенча проректор Ариф Межведиловка Президентның Рәхмәт хаты тапшырылды.

Утырышны йомгаклап, Рөстәм Миңнеханов: «Без монда тыңлап утырыр өчен генә килмәдек. Уку йортына ничек ярдәм итү, аны үстерү турында уйларга кирәк. Вуз үзенә бирелгән статусны аклый. Биредә башкарылган һәр эш республиканың, илнең киләчәге өчен эшләнә. Университетта алган белемнәрнең кыйммәтен бәяләп тә бетереп булмый!» – диде.

● Ватанны саклаучылар көне

# Һәрбер ир-егет Ватан сакчысы булырга тиеш!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Халыкара хатын-кызлар көнендә ир-егетләребез турында язып утыруны актуаль түгел, дияргә ашыкмагыз. Әйе, алар, беренче чиратта, Ватан сакчылары. Ә Ватан ул гаиләне – әниләрне, апа-сеңелләрне, гомумән, асыл затларны үз эченә сыйдыра.

Ватан алдындагы төп бурычын үтәп кайткан, патриотик тәрбия бирү буенча дәреслекләр авторы һәм бүгенге көндә запасчы майор торучы Педагогика һәм психология институты профессоры Әнвәр Хуҗиәхмәтовның фикерләрен белешергә булдым. Түбәндәге юллар сезнең өчен дә, хөрмәтле егетләребез, уйландырырлык һәм кызыклы булыр дип уйлыйм.

Ватан алдындагы төп бурычын үтәп кайткан, патриотик тәрбия бирү буенча дәреслекләр авторы һәм бүгенге көндә запасчы майор торучы Педагогика һәм психология институты профессоры Әнвәр Хуҗиәхмәтовның фикерләрен белешергә булдым. Түбәндәге юллар сезнең өчен дә, хөрмәтле егетләребез, уйландырырлык һәм кызыклы булыр дип уйлыйм.



«Бүгенге көн белән чагыштырганда, без укыган елларда һәр вузда да хәрби-патриотик тәрбия бирү бик көчле иде. Икенче курстан алып, бишенчегә кадәр, атнага бер тапкыр хәрби кафедрага йөрдек. Бу кафедрадагы тәртип башка хәрби училищелардагы кебек үк катгый иде. Анда безгә билгеле бер звание биреп чыгаралар иде, ләкин оборона министрлыгы бер ел хәрби хезмәт итмичә, шул исемне расламый иде. Укуны тәмамлагач, 1974-1975 елларда Украина Республикасының Житомир өлкәсе Овруч шәһәрендә 555-44нче аерым дивизион частьтә элемтә взводы командиры булып, лейтенант дәрәҗәсендә хезмәт итеп кайттым.

Билгеле, типсә тимер өзәрлек егетләрнең ялган юл белән үзләренә чир табулары безнең өчен бик зур афәт булып тора. Сүз дә юк, техника, фән һәм башка промышленность тармакларының алга китүе белән мактанабыз. Бөтенесе дә бар кебек, ләкин бүген Ватаныбызны саклыйм дип атлыгып торучы ир-егетләребез бик аз, гомумән, илебезнең корыч калканы юк хәзер! Безгә Аллаһ тарафыннан ир-ат статусы бирелгән икән, аның Ватан сакчысы дигән сүзне дә аңлатуын күпләр төшенми кебек... Шуңа күрә бу мәсьәләгә төптәнрәк карарга кирәк. Мәктәптә башлангыч хәрби әзерлек курслары укытмау – илдәге мәгариф системасының зур хатасы, чөнки яхшы егетләр, ватан сакчылары мәктәптән үк тулы әзерлек белән чыгарга тиеш дип уйлыйм.

Хәрби-патриотик тәрбия бирү – ул бик зур мәгънәгә ия төшенчә. Бердән, ир-атның үз-үзен тотуын, икенчедән, үз ишләре белән гадел аралашу дәрәҗәсе, хәтта төз, матур итеп йөри белүе дә нәкъ менә хәрби әзерлектән тора! Миңа калса, ир-егет үз-үзен һәм илен, дөрестән дә, хөрмәт итә икән, ул Ватан алдындагы хәрби бурычын үтәргә тиеш!»

Бу сүзләр белән килешмичә мөмкин түгел. Шуңа күрә, егетләр, хәрби хезмәткә барудан курыкмагыз! Сезне һәрвакыт яратучы, сагынып көтүче, назлы хатын-кызлар барлыгы хакында онытмагыз!

● Универ хәлләре

**Башы 1нче биттә.**

**6 МАРТ КӨННЕ** Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты кунагы, Токиодагы Европа тикшеренүләр үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре **DR. HIDEKI HAYASHI** «Европа кризисы дәресе: яңа икътисади тәртип? Япон перспективасы» исемле лекциясе белән инглиз телендә **ЧЫГЫШ ЯСАДЫ**. Ул кризис белән көрәшер өчен кирәк булган кыска һәм озак вакытлы чараларга тукталды.

• • • •

Казанда француз теле буенча **«LA DICTEE DU CONSUL»(NIVEAUB2-C1)** исемле **ХАЛЫКАРА КОНКУРС ҮТКӘРЕЛДЕ**. Филология һәм сәнгать институтының роман-герман филологиясе бүлеге студентлары төбәк этабында катнашып, «Etudiants linguistes» категориясендә призлы урыннар яулый алдылар. Менә алар: Дарья Мельник – I урын, Илья Корзунин – II урын, Анна Павлова – III урын, Екатерина Мясникова – IV урын.

• • • •

**6 МАРТ КӨННЕ** Тарих музее һәм КФУның **ХАТЫН-КЫЗЛАР ЛИГАСЫ ТРЕСКИННАР ГАИЛӘСЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ИҖАДИ КИЧӘ ОЕШТЫРДЫЛАР**. Анда ТРның халык артисты, КФУның Кайгыртучанлык советы әгъзасы Эдуард Трескин, шагыйрәләр Галина Свинцова һәм Полина Ольденбург үзләренең романслары, җырлары, шигырьләре белән тамашачыларның күңелләрен күрделәр.

• • • •

Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан бүген Алабуга филиалында **БӘЙРӘМ КОНЦЕРТЫ**, Чистай филиалында **ТАНТАНАЛЫ УТЫРЫШ**, Универсиада авылында студентлар арасында **«МИСС УНИВЕРСИАДА»** бәйгесе оештырылачак. Ә КФУ ректоры катнашында Хатын-кызлар лигасы оештырган **«ЕЛ ХАТЫН-КЫЗЫ»** конкурсына нәтиҗәләр ясалачак.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

● Халыкара хатын-кызлар көне

# Бердәнбер Хатын-кызлар лигасы

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Җирнең гүзәллеге – хатын кызларда. Бу сүзләр юкка гына әйтелмәгән, чөнки алар – зур илаһи көчкә ия, гүзәл, мөлаем һәм шул ук вакытта җитез, кыю, курку белмәс күркәм затлар. Нәкъ менә шундый сыйфатларга ия, дөньяны үзгәртергә әзер булган дүрт меңгә якын хатын-кыз безнең уку йортында эшли.

Татарстанда, университетыбызда һәм, гомумән, җәмгыятьтә хатын-кызларның дәрәҗәсен күтәрү максатыннан, КФУда мәркәзебездәге беренче иҗтимагый оешма – Хатын-кызлар Лигасы барлыкка килде. Лига составына кергән һәр хатын-кызны уку йортына мәхәббәт, уртак максатлар һәм идеяләр берләштерә. «Профессиональ мөмкинлекләребезне, күңел сизгерлегебезне исәпкә алып, безнең Лига яңа аралашу форматы, институтлар һәм факультетлар арасындагы көчле бәйләнеш һәм хезмәттәшлек нигезендә оешырга тиеш»,– ди Лига җитәкчесе Ирина Терентьева.

Лиганың төп эшчәнлеге булып, хатын-кызлар, университетның рухи мәдәнияте проблемаларына бәйле фәнни-гамәли конференцияләр, түгәрәк өстәлләр уткәрү тора. «Хатын-кызлар диалогы» түгәрәк өстәле – еш үткәрелә торган чараларның берсе. Ана һәм бала мөнәсәбәте, социаль дәрәҗә, сәяси вәзгыять һ.б. темалар, аралашу форматы – биредә бернәрсә дә чикләнмәгән. Шулай ук оешма дәүләт эшләреннән дә читтә калмый. Шулай да Лига әгъзаларының төп игътибарын гаилә темасы алып тора. Алар гаиләдәге мөнәсәбәт, аталар һәм балалар кебек проблемаларны чишү юлларын бергәләп эзлиләр. Гаиләдә бәхетле булу өчен, алдан әзерләнергә кирәк. Күп кенә шәхси мәсьәләләрне хәл итәргә психолог ярдәм итә.

Лиганың оешканына бик аз вакыт узса да, гүзәл затларыбыз ирешкән уңышлары, үткәргән файдалы чаралары белән мактана ала. Менә Хатын-кызлар көне уңаеннан да алар ярдәме белән уку йортында бүген бик зур чара – «Ел хатын-кызы» конкурсына йомгак ясау тантанасы уза. Лига һәм конкурс нәтиҗәләре, анда җиңү яулаган хатын-кызларыбыз турында тулырак итеп газетабызның алдагы саннарында укый алырсыз.

## Ничек? Кайда? Кайчан?

*☛ Кайбер галимнәр гүзәл затлар бәйрәменең нигезе борынгы Римда ук салынган дип әйтә. Ул чорда шәһәрнең иркле хатын-кызларына ирләре бүләкләр биргән, кол хатын-кызлар бу көнне ял иткән.*

*☛ 1857 елның 8 мартында Нью-Йорк шәһәренең аяк киеме чыгару фабрикасы эшчеләре эш сәгатен кыскарту һәм хезмәт хакын ир-атларныкы белән тигезләү таләбе белән манифест оештырган. Шуннан соң Америкада тарихтагы беренче хатын-кызлар профсоюзы оешкан.*

*☛ Европада иң беренче халыкара хатын-кызлар көне 1911 елның 19 мартында берничә илдә генә – Германия, Австрия, Швейцария һәм Даниядә бәйрәм ителгән.*

*☛ Россиягә, төгәлрәге, Петербургка ул 1913 елда килеп җиткән. Әле 19 гасыр ахырында феминисткалар гына билгеләп үткән көнне БМО 1975 елда гына таныган. Шулай да, хатын-кызларның хокукларын ир-атларныкы белән тигезләргә чакырып, гүзәл затларны көрәшкә күтәргән Клара Цеткин үз дигәненә ирешкән.*

*☛ Хәзерге тарихчылар исә, кайбер мәгълүматларны тикшергәннән соң, әлеге бәйрәм хатын-кызларга хас булмаган өлкәләрдә уңышка ирешкән гүзәл затларга багышланган дигән фикердә тора.*

● Чара

# «Scopus»ка ничек эләгергә?

**Башы 1нче биттә.**

Бүген фәнни журналларның роле үскәннән-үсә. Шушы шартларда «Scopus» системасы көн саен яңартылып тора торган дөньякүләм бердәм мультидисциплинар реферативмәгълүматлар базасын тәшкил итә.

Аның мөһим өлешләренең берсе булып, эзләнүләр системасына беркетелгән цитаталау турындагы мәгълүмат тора.

Ольга Кириллова иң элек «Scopus»ны аның төп конкуренты Web of Science сервисы белән чагыштырды. Шуны да билгеләп узарга кирәк: беренче система, икенчесеннән аермалы буларак, гуманитар һәм сәнгать юнәлешле басмаларны үз эченә кертми, аның каравы табигать фәннәрен һәм техниканы киң колачлый. Ольга Кириллова сүзләренә караганда, бүген «Web of Science»да – 12 мең, ә «Scopus»та 20 мең журналдан алынган мәгълүмат тупланган.

Ике сәгать буе барган әлеге семинарда галимнәр өчен мөһим булган берничә мәсьәлә каралды. Ольга Кириллова журналларны «Scopus» системасына сайлап алуга таләпләр һәм экспертизага тәкъдим итү кагыйдәләре хакында аеруча җентекләп сөйләде. Журналны сайлап алу критерийлары, нигездә, һәр индексның эчке сәясәтеннән чыгып билгеләнә. Әмма шулай да төп таләпләр билгеләнгән һәм алардан башка фәнни журнал экспертлар комиссиясе тарафыннан каралмаячак. Нинди таләпләр соң алар? Беренчедән, журналдагы һәр мәкаләнең инглиз телендәге аннотациясе бирелгән һәм иң мөһим сүзләре күрсәтелгән булырга, икенчедән, басма тәкъдир ителгән чыгару вакытын төгәл сакларга тиеш. Шулай ук мәкаләләрдәге мәгълүматка актуальлек, төгәллек, академиклык кебек мөһим сыйфатлар хас булу да зарур.

Ольга Кириллова сүзләренә караганда, журналларны чыгаруга рөхсәт бирелмәүнең сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Иң беренче чиратта, «йорт» журналлары, ягъни үз институты мәкаләләрен генә бастыра торган журналлар кире кагыла. Исеме җисеменә туры килмәгән, юнәлеш-максатлары артык тар булган, цитаталау кулланылмаган басмалар да сайлаудан төшеп кала.



Диана Поварова фотосы

Әдәби сәйләннәр

# Очрашырбыз әле...



Сезгә бу фамилия яхшы таныш. Без Нурсәянен ижаты белән алдагы саннарда таныштырган идек. Бүген үзе турында да мәгълүмат житкерәбез. Минзина Нурсәя Минсур кызы 1994 елнын 5 ноябрендә Арча районы Иске Му авылында туган. Курса Почмак мәктәбен яхшы билгеләргә генә тәмамлап, КФУның татар филологиясе бүлегенә укырга керә. Хикәяләр яза. Аларда мәктәп тормышы, яшьлек, мәхәббәт темаларын яктырта. Хыялы – радиода эшләү.

Ләйсән инде менә ничә көн шифаханәдә ята. Күңеленә килгән уйлар аны әллә кайларга илтә, очыра. Йөрәкне нидер ерта, газаплый, бер туйганчы елыйсы, кемгәдер сыенасы килә. Эх, ничек рәхәт булыр иде, тик кемгә? Әйе, кемгә?.. Юк, юк бу уйлардан арынырга кирәк. Ничек инде кемгә? Ә әниең, сине өзелеп яратучы әниең, шул хакта уйларга кирәк. Әйе, әнисе аның янына көн дә килеп йөри, тик бу вакытта Ләйсән гел йоклый яки ул бик аз вакытка гына кереп чыга. Әлбәттә, әнисенең эше күп, гаиләне карыйсы, туендырасы бар.

Гаиләдә Ләйсән генә түгел бит, энесе Раушан бар. Ул бераз сансызрак малай булды, бер сүзне юньләп тыңламый. Болай үзе яхшы малай, ярдәм сорасаң, баш тартмыйча эшли. Тик кайчак киресе килеп ала торган гадәте бар, шул чакта инде күндерәм димә, колак та салмый. Әнисе аның өчен бик борчыла. Әле тагын имтиханнары җитә. Ни генә уйлап йөри икән бу малай? Ләйсәннең уйлары тагын әллә кая кереп китте...

Һәлакәткә очраган көнне Ләйсән начар хәтерли... Уку йортыннан кайтып бара, кәефе яхшы, күңеле оча, яхшы билге алды бит! Моны, кичекмәстән, әнигә әйтергә кирәк, дип уйлады һәм кесәсеннән телефонын алды. Әһә, менә, менә, әнинең номеры, хәзер шалтыратып алам, дип уйлады. Тик бу вакытта бик зур тизлек белән килгән машинаны күрмәде. Җитмәсә, светофордагы яшел төс тә алга дәште. Машина нинди тизлек белән килгән булса, шулай узып та китте. Ләйсән гәүдәсенең каты итеп авыртуын гына сизде...

Күзләрен ул 3 көн үткәч кенә ачты. Шушы хәлне искә төшерүгә, күзләре яшьләнә. Кайчан аякка баса әле ул?! Көтмәгәндә палатага бер егет килеп керде. Кыз бераз аптырап калды: кулында чәчәкләр, йөзе моңсу, куркынган... Ләйсән йоклаганга салышты. Башта егет кыз янына килде, өстәленә җиләк -җимеш куйды,ә чәчәк бәйләмен вазага утыртты. Сәер,бу чит егет ни өчен аның янына кергән? Ә чәчәкләр нигә? Бәлки, ялгыш кергәндер... Озак тормады, егет чыгып китте. Кыз күзләрен зур итеп ачты да, бер чәчәккә, бер ишеккә карады. Ни уйларга да белмәде ул. Бер яктан, күңеле күтәрелеп китте, икенче яктан, билгесезлек биләп алды. Шулчак бүлмәгә шәфкать туташы килеп керде. Кызның күңелен күтәрергә теләп, шаярта башлады.

- Күрәм, күрәм, туташ, сезнеңчә әйткәндә, «поклонникларың» бар икән.

- Кыз берни әйтмәде, бары башын гына какты.

- Ә, син белмисең бит әле, ул көн дә синең янга килеп йөрде. Керә дә, гафу ит мине, дип чыгып китә. Бүген күрдеңме соң?

- Әйе, күрдем. Кем соң ул?

- Белмим, – дип котылырга уйлады ак халатлы апа. Ләйсән аның нидер яшергәнен сизде.

- Беләсез бит, әйтмисез генә. Әйтегез инде...

- Төгәл мәгълүматтырмы, белмим, тик күрше бүлмәдәге хатыннарның сүзе генә, ул сине бәрдергән егет бугай.

- Ләйсән бу сүзләрдән соң бер мәлгә югалып калды һәм коры тавыш белән генә:

- Бүтән кертмәгез, килмәсен! – диде дә борылып ятты.

- Ләйсәннең тәне генә түгел, җаны да авырта башлады. Кешенең оята кайда? Әле чәчәкләре дә бар. Миңа нигә алар, минем йөрисем, тизрәк терелəсем килә. Күңелемне йомшартмакчы буладыр, юк инде, газаплансын әле, дип уйлады. Озак кына йоклый алмыйча ятты.

- Икенче көнне Ләйсәнне кояш нурлары иркәләп уятты. Күзләрне камаштыра, җылы, рәхәт, күңелдә яшәү дәрте дә көчәйде. Шулчак шәфкать туташы килеп керде.

- Күрәм, хәлләр яхшы.

- Әйе, ярыйсы, авыртулар сизелми. Мин кайчан аякка басармын икән?

- Тиздән, бик тиздән. Табиб шулай диде, – дип, чыгып китәргә әзерләнде.

- Гафу итегез, сез миңа нидер әйтергә телисезме әллә? Тик куркасыз бугай, әллә уңайсызланасызмы?

- Ни... теге егет тагын керергә маташты. Кичә, син йоклагач, кертмәдек. Ул тәрәзәдән керергә булган. Сакчы күреп алган да бер бүлмәгә ябып куйган. Бүген чыгарган идек, синең янга кертегез, дип башыбызны катыра. Аның сиңа әйтер сүзе бар бугай, сөйләшеп алыгыз инде.

- Ярый, тагын килсә, сөйләшермен.

- Ул монда. Сөйләшмичә кайтып китмим, ди. Чакырыйммы?

- Керсен.

- Озак та үтмәде, бүлмәгә теге егет килеп керде. Башын да күтәрмичә, ишек төбендә басып калды.

- Ник кермисең? Уз түргәрәк, күрим сине, – дип, сүзне бераз дорфарак башлады кыз.

- Беләм, син мине күрә алмыйсың. Гафу ит...

- Гафу итәмме, юкмы, барыбер берни үзгәрмәячәк бит.

- Әйе, үзгәрми. Барыбер гафу ит мине. Бик кызганыч, мин ул вакытта онытылып киттем. Әни шалтырата иде, йөрәге авыртып егылган. Шифаханәгә алып китteләр, диде. Бик борчылдым һәм руль артында икәнемне онытып җибәрдем.

- Кыз, берни дәшмичә, читкә карап ятуын дәвам итте.

- Беләм, бу кичерү өчен сәбәп түгел. Машинага утыргач, үзең турында гына уйларга ярамый. Бар игътибар юлда булырга тиеш.

- Ә син нигә гел килеп йөрисең? Тәрәзәгә дә менгәнсең икән...

- Белмим, үзеннән-үзе синең янга тарта. Үземне кичерә алмыйм... Мине хәзер алып китәләрдер инде.

- Кая алып китәләр?

- Кеше бәрдердем бит, төрмәгә.

- Юк, кирәкми. Әниең янында бул, аңа хәзер син кирәк. Минем сүзгә дә колак салырлар бит?! Миңа инде унсигез!

- Синең янга качып киләм мин. Бүген үзем барам. Ни булса, булсын. Иң мөһиме: синнән гафу үтендем.

- Бәлки, син хаклыдыр... Бар, - дип, кыз тыштан гына аның фикерен хуплады, үзе кызганып куйды. Мин сиңа карата эш ачмауларын сорармын.

- Хуш, мин киттем. Берәр вакыт күрешербез әле. Син дә аякка басарсың. Аннары икәү, урам буйлап, кулга-кул тотынышып йөрербез. Икебезгә дә бу вакытта рәхәт, тыныч, йөзләребез көләч, бәхетле булыр, – диде дә кызның башыннан сыйпап чыгып китте.

Кызның күңеленә бу сүзләр бик нык тәэсир итте. Ни сәбәптән елаганын ул әле үзе дә белми иде...

Сәламәтлек

# Беренче тиен. Кайчан һәм ничек?

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты

Иртәме-соңмы һәрберебездә акча эшләү теләге яки зарурлыгы туа. Үзвакытында кемдер шешә, икенчеләр макулатура, өченчеләр исә каен яки нарат бөресе җыеп-сатып, тәүге сумнарын эшләгән... Беренче мәртәбә кесәгә кергән акчаның кадерен үзең генә беләсең! Әнә бит Голливуд йолдызлары да түбәннән күтәрелгән. Мисал өчен, күренекле Сильвестр Сталлоне беренче «хезмәт хакы»н зоопаркта читлекләр чистартып, Бред Питт чеби киеме киеп, урам буенча флаерлар таратып эшләгән. Американы Фрейзер Доэрти 14 яшендә кайнатма ясап сату белән шул тикле мавыгып киткән ки, 21 яшенә 1 миллион доллардан артык табыш туплаган. Марк Цукерберг, Оксфорд университетында укыганда ук, Facebook челтәренә нигез салып, беренче миллионын эшли. Ә безнең университетны тәмамлап, тормышка юл алган элекке студентларыбыз беренче тиеннәрен кайда, кайчан һәм ничек эшләп тапкан икән? Бу сорау белән аларның үзләренә мөрәҗәгать иттек.

**Рамиль Әсхәдуллин, җырчы, композитор; элеккеге ТДГПУның музыка факультеты:** Беренче тиеннәрне 14-15 яшьтә эшләп алырга туры килде. «Мунча ташы» театрына музыкаль бизәлешләр әзерли идем. Суммасын хәтерләмим дә инде хәзер. Студент чакта баянда аккомпаниатор булып акча эшләп йөрдем.

**Айсылу Лерон. «Татар радиосы» ди-джее, КФУның журналистика һәм социология факультеты:** Беренче хезмәт хакымны (100 сум иде) 12 яшемдә алдым. Ул чакта телевидениедә эшли идем. Студент чакта да ТВда эшләвемне дәвам иттем һәм күпләр эти-әнисе биргән акчага яшәгән вакытта, мин инде хәйран гына хезмәт хакы ала идем. Гомумән, 17 яшемнән өйдән акча алганым юк, Аллага шөкер!


**Илфар Кәримов, «Яңа гасыр» радиосы ди-джее, КФУның журналистика һәм социология факультеты:** Беренче хезмәт хакын 9 сыйныфта укыганда алган идем: җәй буе авылларга газ үткәрдек. Якынча 4-5 мең сум тирәсе чыкты. Ә 10да укыганда, комбайнчы ярдәмчесе булып тир түктем. Хезмәте ачы булса да, җимеше татлы.

**Роза Әдиятуллина, «Яңа гасыр» телевидениесе алып баручысы, КФУның журналитика һәм социология факультеты:** Беренче эшләп алган акчаны хезмәт хакы дип атарга тел дә әйләнми. Мәктәптә укыганда, «Яшьләр тукталышы» тапшыруына төшерелгән берничә сюжет өчен 300 сум бирделәр! Шуңа ничек сөенгәнемне әле дә хәтерлим. Бу акчага, базарга чыгып, күзлек сатып алдым. Аннан шуны «Үзем эшләп алдым» дип, горурланып киеп йөрдем. Җәй көннәрендә Яр Чаллы шәһәрендәге балалар, студентлар лагеренда әйдаман булып эшләдем, аннан да хәйран гына «тамды». Мәктәпне тәмамлау белән, ТНВга штатка алдылар, шуннан башланды инде тулы канлы хезмәт хакы алуларым!

**Айваз Садыров, КФУның журналитика һәм социология факультеты:** Тәүге акчаны 5 сыйныфта укыганда эшләвем бүгенгедәй хәтеремдә. Мәктәбебездә өстәл теннисы түгәрәге ачылган иде, бөтен мәктәп укучысы җенләнеп шунда йөри башлады. Авылда булганга, күпләрдә ракетка һәм теннис шарлары юк иде. Кемдер ракетканы үзе ясаса, кемгәдер теннис кирәк-яракларын өлкәннәр шәһәрдән алып кайтып бирә. Шунда мин, аларны сатып, акча эшләп булачагын аңлап алдым. Әти шәһәрдән «оптом» ракетка һәм шарлар алып кайтып бирде. Шуның бәясен арттырып сатып, бик уңышлы гына эшмәкәрлек итеп алдым. Җәйгә җыелган акчага велосипедлы булып куйдым..

Игътибар!

Сабыйлар өчен чыга торган «Тылсымлы куллар» журналы белән якыннан танышасыгыз киләме? Мавыктыргыч эчтәлекле, сыйфатлы кәгазьдә басыла торган журналны өйгә яздырырга мөмкин.




DARELFØNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1 й. 317 оф.